
Сарман муниципаль районының муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе " Җәлил гимназиясе»
Эшләде: 5 сыйныф укучысы Романов Имиль Дамир улы
Укытучы: Миннебаева Гүзәлия Абрар кызы

# “ Мәңге шулай тыныч булсын авылым таңнары”

КУШЛАВЫЧ

Кушлавыч авылы Казан ханлыгы чоры авыллары исемлегендә искә алына. 1676 елның 24 июль датасы белән авыл атамасы И. П. Ермолаев хезмәтендә теркәлгән.



Авыл Арча районында урнашкан



1898 нче елда  бер агач мәчет, кибет һәм тимерче алачыгы булган. Кушлавыч авылы И. А. Износков китабында телгә алына. Анда 120 хуҗалык булып, ислам динендәге 411 ир-ат, 383 хатын-кыз яшәгән. Халык умартачылык белән шөгыльләнгән. 1898 елгы исемлектә Кушлавыч авылында татарлар яши дип искә алына. К. П. Берстель мәгълүматларына караганда, авылда барлыгы 798 татар кешесе яшәгән.



Авыл тау башына салынган. Ул Красна елгасының ике ярына урнашкан һәм ике зур урамнан тора.




Авылның үзенең җил тегермәне, мәдрәсәсе булган.





Белгәнебезчә, әлеге авыл Габдулла Тукай белән бәйле.

Кушлавыч авылында 1886 елның 14 (26) апрелендә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай дөньяга килә.



Кушлавычта Тукайның музее бар. Әлеге рәсемдә Тукайның әнисенең савыт –сабалары.



Авыл мәчете.



# Кушлавыч авылында “Тукай “ чишмәсе



Кушлавычта китапханә һәм Тукай һәйкәле.



Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларына һәйкәл.



**Туган авыл**

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.
Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.
Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.